Республика Татарстан
САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САБА ШӘҺӘР
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2024 ел № 170

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының 19.08.2016 елның №107 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 24.10.2022 №1885 Карары кабул ителүгә бәйле рәвештә,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында» 19.08.2016 елның №107 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2. пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешма җитәкчесе янгынга каршы ишекләрне, шулай ук ишек токталарын, “антипаник" йозак җайланмаларын, җитештерүче тарафыннан каралган тыгызлауларны һәм ишек бусагаларын, ә баскыч мәйданчыклары ишекләрендә, эвакуацион чыгу ишекләрендә, шул исәптән подвалдан беренче катка алып баручы ишекләрдә (фатирларга, коридорларга, вестибюльләргә (фойе) һәм турыдан-туры тышка алып баручы ишекләрдән тыш) үз-үзен ябу җайланмаларының булуын һәм төзеклеген тәэмин итә.».

1.2. 3.2. пунктны. түбәндәге эчтәлектә өченче абзац итеп өстәргә:

"Янгынга каршы яки төтенгә каршы ишекләрне (җайланмаларны) нормаль ябуга комачаулый торган нинди дә булса җайланмалар урнаштыру рөхсәт ителми.»;

1.3. 4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Эвакуация юлларындагы ишекләр, янгын куркынычсызлыгы норматив документлары таләпләре буенча ачылмый торган ишекләрдән тыш, бинадан чыгу юнәлешендә дә иректе ачылырга тиеш.

Катлы коридорлардан, холллардан, фойелардан, вестибюльләрдән, баскыч шакмакларыннан, зал бүлмәләреннән эвакуация чыгу ишекләрендәге бикләүләр (йозаклар), биналарны карап тотуның (саклау, иминлекне тәэмин итүнең) махсус режимы билгеләнгән саклау объектларыннан тыш, аларны эчтән ачкычсыз ирекле ачу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Биналарны карап тотуның (саклауның, иминлекне тәэмин итүнең) махсус режимы билгеләнгән, мондый биналарның ишекләрен эчтән ачарга мөмкинлек бирми торган саклау объектлары өчен бинаның янгыннан саклау системалары сигналы буенча һәм (яисә) тәүлек буе сак белән шөгыльләнүче хезмәткәр (эшче) тарафыннан эвакуация чыгу ишекләренең бикләрен автомат рәвештә ачу тәэмин ителергә тиеш.»;

1.4. 5.12 нче пунктның икенче җөмләсендә «Янгын щитларының кирәкле саны һәм аларның тибы билгеләнә» сүзләрен «Янгын щитларының тибы билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 5.13. һәм 5.14.пунктларны юкка чыгарырга;

1.6. 5.15 пунктны 5.13 пункты дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Г. Гыйлманов